ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.10.2025 с.Старое Дрожжаное № 419

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү буенча советның яңартылган составы турында

Ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү һәм Чүпрәле муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы ихтыярыйлык берләшмәләр эшчәнлегенә ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 09 сентябрендәге 391 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү буенча совет төзү турында»гы карары белән төзелгән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлар) үстерү буенча советның яңартылган составын кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлык) үстерү буенча совет төзү турында» карарының 2.2 пунктын һәм 2 нче кушымтасын үз көчләрен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Җитәкче Р.И. Мөхәммәтҗанов

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның "28" 10 419 номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү буенча советның составы

Залялов А.Ф. - Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, Совет рәисе;

Вилданов Р.Р. – Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы, Совет рәисе урынбасары;

Шакурова М.В. - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге әйдәүче белгече, Совет секретаре.

Совет әгъзалары

Хәлиуллов Г.Ф. - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы;

Сәгъдиев З.Ф. - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге» МКУ башлыгы;

Рәкыйпова Л.Р. - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Чүпрәле муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча);

Кукушкин И.В. - «Чүпрәле үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча);

Рәкыйпов И.А. - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе;

Романова Е.А. – Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Созидание» яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» МБУ директоры;

Сөләйманов А.Р. - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Форпост» МБУ директоры;

Фаизова Г.В.- «Туган як» газетасының баш мөхәррире (килешү буенча).

Эшләр идарәчесе: Д.Р. Сабирзянова